МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г.Казань **БОЕРЫК**

**_11.05.2023__** **№ _167/2-пр_**

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге 68-ПУ номерлы Указы нигезендә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 23 декабрендәге 372/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2022 елның 14 февралендәге 19/2-пр номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) таяна.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров